**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 29 гыйнварындагы 154 номерлы карары**

**Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Гудованцев урамында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 68 кв.м;

- үзләренә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:221231:6, 16:50:221231:3, 16:50:221231:2, 16:50:221231:8;

- үзенә карата хокуклар чикләнә торган квартал – 16:50:221231;

- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Авиатөзелеш районы, Гудованцев урамы;

- билгеләү максаты: электр челтәре хуҗалыгы объекты – җирле әһәмияттәге ТП-689 трансформатор подстанциясе урнаштыру;

- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, милек хокукы җирле әһәмияттәге ТП-689 трансформатор подстанциясенә карата теркәлгән (2001 елның 26 декабрендәге №16-50.3-23.2001-1364.3).

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 29 гыйнварындагы
154 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Гудованцев урамында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:250
Координаталар системасы: МСК-16

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | кызыл линияләр |
| 16:50:221231 | кадастр кварталы |
| 16:50:221231:6, 16:50:221231:3, 16:50:221231:2, 16:50:221231:8 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |